Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Урман Кәләй авыл җирлегенең
Колшәрип тимер юл станциясе бистәсе торак пунктында гражданнар җыены
нәтиҗәләре турындагы карары

12 ноябрь 2021 ел №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2021 елның 11 ноябрендәге 09 сәгать 00 минутта узган гражданнарның этаплы җыен нәтиҗәләре нигезендә "Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман - Кәләй авылы җирлеге Колшәрип тимер–юл станциясе бистәсе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 2500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: Колшәрип тимер –юл станциясе бистәсен дә юлларны норматив хәлгә китерү, сметалар төзү өчен түләү , техник күзәтү үткәрү һәм җирлек милкенә рәсмиләштерү?»сораулары буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 18 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 12 кеше, бу 66% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 12-е «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде;

гражданнар җыенында катнашучыларның 0-е «КАРШЫ»позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карарбирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман Кәләй авыл җирлегенең Колшәрип тимер юл станциясе бистәсе торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2.Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман Кәләй авыл җирлегенең Колшәрип юл станциясе бистәсе авылында яшәү урыны буенча теркәлгән, даими яшәүче булган һәр балигъ булган кешедән үзара салым средстволарын 2022 елда 2500 сум күләмендә кертергә.

3. Җыелган үзара салым средстволарын җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә: Колшәрип тимер –юл станциясе бистәсен дә юлларны норматив хәлгә китерү, сметалар төзү өчен түләү, техник күзәтү үткәрү һәм җирлек милкенә рәсмиләштерү.

4.Әлеге карарны«Альметьевский вестник» газетасында бастырырга, Колшәрип тимер юл станциясе бистәсе территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә,«Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматларрәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайты«Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче Л.Н. Фәләхиев